КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 23 апрель г.Казань № 509

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында Баулы шәһәренең әйләнгеч юлы төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында 1 нче кушымтада күрсәтелгән, 168 758 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләреннән барлыкка килгән 2 005 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә. Алына торган җир кишәрлекләре В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре милекчесе) милкендә тора.

2. Җир кишәрлекләрендә урнашкан һәм 2 нче кушымтада күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектлары алынмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

3.1. 10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлекләре милекчесенә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне.

3.2. Җир кишәрлекләрен алу турында килешүләр төзүне.

3.3. Алына торган җир кишәрлекләре өчен түләүләрне түләүне.

4. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын раслау турында» 2023 елның 5 июлендәге 140 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә алына торган җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләрен башкаруны;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алына торган җир кишәрлекләре өчен түләүләр күләмен билгеләүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен түләүләр күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында килешүләр (алга таба – килешүләр) әзерләүне һәм аларны алына торган җир кишәрлекләре милекчесенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре милекчесе тарафыннан имзаланган килешүләр законнар белән билгеләнгән срок эчендә тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 23 апрель, 509 нчы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен
алынырга тиешле җир кишәрлекләре
исемлеге

| Кадастр номеры | Урнашу урыны | Мәйданы, кв.метр | Алына торган мәйдан, кв.метр | Милекчесе |
|---|---|---|---|---|
| 16:11:130803:14 | Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре | 523 | 58 | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте |
| 16:11:130801:14 | Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Потапово-Томбарлы авыл җирлеге | 9 089 | 356 | |
| 16:11:130801:34 | | 1 268 | 52 | |
| 16:11:130803:21 | | 9 924 | 76 | |
| 16:11:130801:36 | | 1 356 | 77 | |
| 16:11:000000:2372 | | 57 097 | 146 | |
| 16:11:130803:985 | | 35 483 | 320 | |
| 16:11:130801:49 | | 390 | 36 | |
| 16:11:130801:57 | | 15 | 15 | |
| 16:11:130801:53 | | 1 830 | 106 | |
| 16:11:130801:59 | | 465 | 37 | |
| 16:11:130803:19 | | 13 | 13 | |
| 16:11:130801:367 | | 1 908 | 77 | |
| 16:11:130801:52 | | 583 | 137 | |
| 16:11:130801:332 | | 48 814 | 499 | |
| Барлыгы | | 168 758 | 2 005 | |

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 23 апрель, 509 нчы
карарына 2 нче кушымта

Җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объектының кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объекты исеме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 16:11:000000:2372 | 16:11:130803:1020 | «3384 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1019 | «3376 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1018 | «3372 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1017 | «3379 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1016 | «3381 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1015 | «3378 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1014 | «3382 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1010 | «3377 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1009 | «3374 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1025 | «3373 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1024 | «3386 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1023 | «3380 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1021 | «3387 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1022 | «3385 номерлы скважина» |
| | 16:00:000000:69231 | ««Баулынефть» нефть-газ чыгару идарәсенең Баулы нефть ятмалары урынын төзекләндерү» |
| | 16:00:000000:69356 | «Баулы нефть ятмалары урынын төзекләндерү. «Баулынефть» нефть-газ чыгару идарәсе» |
| 16:11:130803:985 | 16:11:130803:997 | «3179 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:996 | «3178 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:995 | «3177 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1004 | «3115 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1002 | «3180 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1001 | «3181 номерлы скважина» |
| | 16:11:130803:1000 | «3114 номерлы скважина» |
| | 16:11:000000:2490 | «Баулынефть» нефть-газ чыгару идарәсенең Баулы нефть ятмалары урыннарында чыгару скважиналарын төзекләндерү» |
| | 16:11:000000:2495 | «Баулы нефть ятмалары урыннары скважиналарын үзләштерү» |
| 16:11:130801:332 | 16:11:130801:358 | «УПС-436да тозлы су җыю пункты» |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | 16:11:130801:362 | «Баулы нефть ятмалары урынының ЦДНГ-2 УПС-436 технологик сыеклыкны әзерләү узелы» |
| | 16:11:130801:371 | «ДНС-113нән УПС-436га кадәр нефтьүткәргеч (d 273 × 7 пни)» |
| | 16:11:130801:372 | «УПС-436дан БГ-803кә кадәр суүткәргеч (d 273 × 9 пни)» |
| | 16:11:130801:709 | «498 номерлы скважина» |

___